**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АЙБАШ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур., 1А

**ГЛАВА АЙБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422726, Республика Татарстан,Высокогорский район,
с. Айбаш, ул. Центральная, 1А

тел./факс 8(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**2 ноябрь 2021 ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Зур Көек торак пунктында гражданнарының үзара салым акчаларын җыю һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

."Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, 25.1 ст.нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, ст. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең 22 Уставы һәм 2019 елның 23 октябрендәге 162 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карар нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Зур Көек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 13 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Зур Көек авылы, Үзәк урам, 34 нче йорт адресы буенча (китапханә янында) билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Зур Көек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?”

а) авыл эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш салу, асфальт түшәк җәю)

б) урам утларын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Сафиуллин